РЕСПУБЛИКА ТАТАРСТАН
НИЖНЕКАМСКИЙ
ГОРОДСКОЙ СОВЕТ

ТАТАРСТАН РЕСПУБЛИКАСЫ
ТҮБӘН КАМА
ШӘҺӘР СОВЕТЫ

пр. Строителей, д. 12, г. Нижнекамск, 423570

Төзүчеләр пр., 12 нче йорт, Түбән Кама шәһәре, 423570

Тел./факс: (8555) 42-42-66. E-mail: Gorsovet.Nk@tatar.ru

**РЕШЕНИЕ** **КАРАР**

2024 елның 12 декабре № 39

Түбән Кама шәһәр Советының
кайбер карарларына үзгәрешләр кертү турында

Россия Федерациясе Бюджет кодексының 136 статьясы, «Россия Федерациясендә муниципаль хезмәт турында» 2007 елның 02 мартындагы 25-ФЗ номерлы Федераль законның 22 статьясы, Россия Федерациясе Хезмәт кодексының 351.8 статьясы, Татарстан Республикасы Бюджет кодексының 44 статьясы, муниципаль хезмәт турында Татарстан Республикасы кодексының 26 статьясы, Түбән Кама шәһәр Советы

КАРАР БИРӘ:

1. Түбән Кама шәһәр Советының «Түбән Кама шәһәре муниципаль берәмлеге хезмәткәрләренең хезмәтенә түләү турында» 2021 елның 1 сентябрендәге 39 номерлы карарына түбәндәге үзгәрешләрне кертергә:

1.1 пунктта «13 323» санын «13 990» санына алмаштырырга;

1.2 нче кушымтаны яңа редакциядә бәян итәргә (кушымта итеп бирелә);

3 нче кушымтаның 1.3 пунктында:

«эш нәтиҗәләре буенча премияләр» сүзләреннән соң «, шул исәптән остазлык буенча эш башкару» сүзләрен өстәргә;

түбәндәге эчтәлекле абзац өстәргә: «Түбән Кама шәһәренең җирле үзидарә органнарында шактый эш тәҗрибәсе булган остазлар исемлеген һәм остазларга премия түләү тәртибе Түбән Кама шәһәре Мэры тарафыннан раслана. Түләү күләме, Түбән Кама муниципаль районы һәм Түбән Кама шәһәре җирле үзидарә органнарында муниципаль хезмәт вазыйфаларында остазның эшләгән елларын һәм Түбән Кама муниципаль районы һәм Түбән Кама шәһәре муниципаль районы муниципаль вазыйфасында затның муниципаль вазыйфада булу срогын исәпкә алып, муниципаль вазыйфаны биләүче затның айлык акчалата хезмәт хакының 10 проценттан алып 30 процентка кадәр күләмендә билгеләнә.»;

1.4 нче кушымтада:

түбәндәге эчтәлекле сигезенче һәм тугызынчы абзацлар өстәргә:

«- остазлык буенча эшләрне башкару.

Түбән Кама шәһәренең җирле үзидарә органнарында шактый тәҗрибә туплаган остазлар исемлеген һәм остазларга премия түләү тәртибе Түбән Кама шәһәре Мэры тарафыннан раслана. Түләү күләме, Түбән Кама муниципаль районы һәм Түбән Кама шәһәре җирле үзидарә органнарында муниципаль хезмәт вазыйфаларында остазның эшләгән еллары һәм затның Түбән Кама муниципаль районы һәм Түбән Кама шәһәре муниципаль районы муниципаль вазыйфасында булу срогы тиешлеген исәпкә алып, муниципаль хезмәткәрнең вазыйфаи окладының 10 проценттан 30 процентка кадәр күләмендә билгеләнә.».

1. Түбән Кама шәһәр Советының «Татарстан Республикасы бюджет даирәсе хезмәткәрләренең хезмәтенә түләү буенча бердәм тариф челтәре таралмаган Түбән Кама

шәһәре бюджет даирәсенең аерым оешмалары хезмәткәрләренең хезмәтенә түләү турында» 2021 елның 01 сентябрендәге:

2.1 пунктының дүртенче абзацында «13 323» санын «13 990» санына алмаштырырга;

1 нче кушымтаны яңа редакциядә бәян итәргә (кушымта итеп бирелә).

3. Әлеге карар, 2025 елның 1 мартыннан үз көченә керә торган 1.3 һәм 1.4 пунктларыннан тыш, 2025 елның 1 гыйнварыннан үз көченә керә.

1. Җәмәгатьчелек һәм массакүләм мәгълүмат чаралары белән элемтә бүлегенә әлеге карарны Түбән Кама шәһәре Уставында билгеләнгән тәртиптә бастырып чыгарырга, шулай ук Түбән Кама муниципаль районының рәсми сайтында Интернет мәгълүмат-телекоммуникация челтәрендә урнаштырырга.

2. Әлеге карарның үтәлешен тикшереп торуны Түбән Кама шәһәр Советының бюджет сәясәте һәм икътисадый үсеш буенча даими комиссиягә йөкләргә.

Түбән Кама шәһәре Мэры Р.Х. Муллин

Түбән Кама шәһәр Советының
2024 елның 12 деабрендәге
39 номерлы карарына
1 нче кушымта

Түбән Кама шәһәр Советының
2021 елның 1 сентябрендәге
39 номерлы карарына
1 нче кушымта

Муниципаль вазыйфаларны даими нигездә биләүче затларны
акчалата бүләкләү күләме

| № п/п | Хезмәт хакы буенча төркем (муниципаль берәмлек халкы санына карап) | 4 группа |
|---|---|---|
| | | 100 дән 250 мең. кешегә кадәр |
| 1 | Түбән Кама шәһәре Мэры | 38 889 |
| 2 | Түбән Кама шәһәре Мэры урынбасары | 34 998 |
| 3 | Депутатлар | 18 848 |
| 4 | Җирле үзидарәнең сайланулы органнары әгъзалары | 16 019 |

Түбән Кама шәһәре
Мэры урынбасары М.В. Камелина

Түбән Кама шәһәр Советының
2024 елның 12 деабрендәге
39 номерлы карарына
1 нче кушымта

Түбән Кама шәһәр Советының
2021 елның 1 сентябрендәге
40 номерлы карарына
1 нче кушымта

Татарстан Республикасы Бюджет өлкәсе хезмәткәрләренә хезмәт өчен түләү буенча бердәм тариф челтәре кагылмый торган Түбән Кама шәһәре бюджет өлкәсенең аерым оешмалары җитәкчеләренең һәм белгечләренең вазыйфаи окладлары күләмнәрен исәпләгәндә кулланыла торган тапкырлык коэффициентлары

| Вазыйфаның исеме | Коэффициент (IV группа) |
|---|---|
| Оешма җитәкчесе | 2,25 |
| Оешма җитәкчесе урынбасары, баш бухгалтер | 2 |
| Мөстәкыйль идарә (бүлек) җитәкчесе | 1,34 |
| Мөстәкыйль идарә (бүлек) җитәкчесе урынбасары | 1,30 |
| Бүлек җитәкчесе | 1,25 |
| Бүлек җитәкчесе урынбасары | 1,19 |
| Баш белгеч | 1,12 |
| Алып баручы белгеч | 1,07 |
| I категорияле белгеч | 1,01 |
| II категорияле белгеч | 1,00 |
| Белгеч | 1,00 |

Түбән Кама шәһәре
Мэры урынбасары М.В. Камелина